ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
РЫБНО-СЛОБОДСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БАЛЫК БИСТӘСЕ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

08.05.2020 пгт. Рыбная Слобода № 92пи

Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитетының «Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы территориясендә элемтә линияләрен һәм корылмаларының сакланышын тәэмин итү турында» 2020 елның 4 мартындагы 39пи номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

Норматив хокукый актны гамәлдәге законнарга туры китерү максатларында, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Россия Федерациясе элемтә линияләрен һәм корылмаларын саклау кагыйдәләрен раслау турында» 1995 елның 9 июнендәге 578 номерлы карарына таянып, КАРАР БИРӘМ:

1. Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитетының «Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы территориясендә элемтә линияләрен һәм корылмаларының сакланышын тәэмин итү турында» 2020 елның 4 мартындагы 39пи номерлы карарына (алга таба – Карар) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 2.1.пункт карарларын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2.1. Балык Бистәсе районы территориясендә юридик һәм физик затларга, предприятие һәм оешмаларга инженерлык-техник тәэмин итү челтәрләрен һәм башка объектларны төзегәндә, реконструкцияләгәндә һәм ремонтлаганда, элемтә линиясенең саклау зонасында яки радиофикация линиясе (0,3 метрдан да артмаган тирәнлеккә казудан тыш) җир эшләрен башкаруга әлеге элемтә линиясе яки радиофикация линиясе карамагында булган предприятиеләр белән килешмичә рөхсәт бирмәскә.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының рәсми сайтында Интернет-телекоммуникация челтәрендә веб-адрес буенча: http://ribnaya-sloboda.tatarstan.ru урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең инфраструктура үсеше буенча урынбасары Д. Н.Ризаевка йөкләргә.

Җитәкче Р.Л. Исланов